АГЕНТСТВО ИНВЕСТИЦИОННОГО РАЗВИТИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ИНВЕСТИЦИОН ҮСЕШ АГЕНТЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

«11» 12 2024 ел № 44

Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының «Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Комиссиясе турында» 15.02.2016 елгы №13-2/2лс боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турында» 2010 елның 1 июлендәге № 821 Указына үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының «Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Комиссиясе турында» 15.02.2016 елгы №13-2/2лс боерыгына (Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының 16.03.2018 № 5, 23.09.2022 № 52, 27.02.2023 № 4, 24.08.2023 № 27, 07.12.2023 № 48 боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

күрсәтелгән боерык белән расланган Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Комиссиясе турында Нигезләмәдә:

1.3 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба - дәүләт хезмәткәрләре, Агентлык) «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге № 273-ФЗ Федераль законда, коррупциягә каршы тору максатларында башка федераль законнарда (алга таба - хезмәт тәртибенә таләпләр һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләр) билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне, бурычларны үтәвен тәэмин итүдә»;

3.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле «е» пунктчасын өстәргә:

«е) хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәүгә комачаулый торган аңа бәйле булмаган хәлләр барлыкка килү турында дәүләт хезмәткәренә хәбәр итү»;

3.4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында һәм «е» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәләр Агентлыкның коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан карала, ул хәбәрнамәләрне карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмәләр әзерли»;

3.4.2 пунктында «һәм әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д» пунктчасында» сүзләрен «һәм әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д», «е» пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга»;

3.4.3 пунктының «а» пунктчасында «һәм 3.1 пунктының «д» пунктчасында» сүзләрен «һәм 3.1 пунктының «д», «е» «пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга»;

3.4.3 пунктының «в» пунктчасында:

«һәм әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д» пунктчасында» сүзләрен «һәм әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д», «е» пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга»;

«Нигезләмәнең 3.13, 3.15.1, 3.18 пунктлары нигезендә» сүзләрен «Нигезләмәнең 3.13, 3.15.1, 3.15.2, 3.18 пунктлары нигезендә» сүзләренә алмаштырырга»;

3.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән хәбәрнамәләр, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (план буенча) утырышында карала»;

3.8 пунктында «3.1 пунктының «б» пунктчасы нигезендә» сүзләрен «3.1 пунктының «б» һәм «е» пунктчалары нигезендә» сүзләренә алмаштырырга»;

3.8.1 пунктының «а» пунктчасында «3.1 пунктының «б» пунктчасы нигезендә» сүзләрен «3.1 пунктының «б» һәм «е» пунктчалары нигезендә» сүзләренә алмаштырырга»;

түбәндәге эчтәлекле 3.15.2 пунктын өстәргә:

«3.15.2. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «е» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган хәлләр килеп чыгу һәм аның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мөмкин түгеллеге арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булуын танырга;

б) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган хәлләр килеп чыгу һәм аның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мөмкин түгеллеге арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булмавын танырга.»;

3.19 пунктында:

«әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «а»-«д» пунктчаларында күрсәтелгән» сүзләрен «әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «а», «б», «г», «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән» сүзләренә алмаштырырга»;

«әлеге Нигезләмәнең 3.11-3.15.1, 3.17-3.18 пунктларында каралган» сүзләрен «әлеге Нигезләмәнең 3.11-3.15.2, 3.17-3.18 пунктларында каралган» сүзләренә алмаштырырга»;

Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча күрсәтелгән боерык белән расланган Комиссиясе составында:

Комиссия составыннан чыгарырга:
Фугин Владимир Валерьевичны;

Комиссия составына кертергә:
Кривенкова Мария Витальевнаны – хокукый һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге башлыгы, Комиссия рәисе урынбасарын.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче Т. И. Миңнуллина